[library stamp, illegible]

ДҮШӘМБЕ
29 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 23 (5823)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

Ягулык һәм электроэнергия тотуда ныклы режим булдырырга

Халык хуҗалыгының ягулык һәм электр промышленносте зур адымнар белән алга бара. Үткән ел күмер промышленносте Наркоматы үзенең планын 109,2 процент, нефть промышленносте Наркоматы—104,8 процент, электростанцияләр һәм электр промышленносте Наркоматы—107,3 процент, урман промышленносте Наркоматы—105,3 һәм Союзный республикаларның җирле ягулык промышленносте наркоматлары планнарын 108,4 процент итеп үтәделәр. СССР Дәүләт План Комиссиясенең белдерүендәге бу саннар халык хуҗалыгының гаять зур уңышлар белән алга баруы, тайпылышсыз үсә һәм ныгый баруы турында сөйлиләр.

Ягулык һәм электроэнергия кыш көннәрендә аеруча кискен мәсьәлә булып тора. Партия һәм Советлар хөкүмәте бездән һәрбер килограмм ягулыкны, һәрбер киловатт - сәгать электро-энергияне зур саклык белән, экономия белән тотуны таләп итәләр. Шунлыктан, бурыч предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең ягулык балансларын төгәл үтәүдән генә түгел, бәлки зур экономия белән үтәүдән гыйбарәт. Моның өчен ягулык балансының үтәлүен тикшерүне җәй көненә, көннәр җылынуга калдырмаска, бәлки һәр вакыт җентекле рәвештә тикшерә барырга, ягулыкны һәм электроэнергияне әрәм-шәрәм итүләргә каршы кискен көрәш алып барырга кирәк.

Үткән ел Казан электростанцияләре эшендә дә кайбер уңышлар булды. Электроэнергия җибәрү 1938 нче елга чагыштырганда 24 процент артты. 1938 нче елга караганда электроэнергиягә 16,4 процент экономия ясалды. Язу машиналары заводы һәм Трампарк энергиядән файдалануда үрнәк күрсәттеләр. Алар куелган лимитны төгәл рәвештә үтәделәр. „Спартак“ комбинаты җирле ягулыктан (торфтан) зур күләмдә файдалану эшенә кереште, ягулык буенча 2 процент һәм электроэнергия буенча 3 процент экономия бирде. Таш күмеренә экономия ясауда Казан энергокомбинатының үткән ел бөтен Советлар Союзы өчен үрнәк булырлык уңышлары булды.

Хуҗалыкчылар, производство командирлары тарафыннан ягулыкны һәм электроэнергияне саклык белән тотуга җидди игтибар бирелгән предприятиеләрдә бу өлкәдә уңышлар юк түгел. Киресенчә, ягулыкка һәм электроэнергиягә экономия ясауның әһәмиятен аңлап җиткермәгән предприятиеләрдә бу өлкәдә җидди кимчелекләр яшәп килә. Үткән ел „Энергосбыт“ конторасы төрле предприятиеләргә һәм учреждениеләргә электроэнергияне артык тотканнары өчен 240 мең сум штраф салды. „Кызыл Шәрык“ сыра заводы 3 айда гына 15 мең сумнан артык штраф түләде. Серго Орджоникидзе заводы үткән елның декабрь аенда 5 мең сум, 6 нчы тегү фабрикасы—2 мең сум, макарон фабрикасы 1 мең сум штраф түләделәр. Льнокомбинат, „Урак һәм Чүкеч“ заводы, 1 нче мех фабрикасы һәм 4 нче ясалма каучук заводы электроэнергияне әледән-әле артык тоталар, монда станоклар күп вакыт бушка әйләнеп энергияне әрәм итәләр, машиналар тулы нагрузка белән эшләмиләр.

Водоканальтрестның, „Урак һәм Чүкеч“ заводының озак вакытлар буенча электроэнергия тоту нормалары да булмады. Ә Ясалма күн заводы һәм Кинопленка фабрикасы исә кабартылган планнар төзеп, „кирәгеннән артык“, „экономия“ бирәбез, дип күз буяп килгәннәр. Алардагы „саннар“ буенча „экономия“ 40 процент чамасы булып чыга.

Мондый күренешләргә каршы көрәш рәхимсез булырга тиеш. Ягулыкны һәм электроэнергияне артык тотып, завод һәм фабрика яки учреждение кассасыннан унар, йөзәр мең сум акчаны җилгә җибәрүче кешеләр каты җавапка тартылырга тиешләр.

Хезмәт җитештерүчәнлегенең бишьеллык планын дүрт елда үтәү өчен көрәштә ягулыкка, җылылыкка экономия ясау гаять зур урын тотканлыкны һәр вакыт истә тотарга кирәк. Кочегарлар һәм электр промышленносте эшчеләре арасында социалистик ярыш бөтен киңлеге белән җәелергә һәм экономия өчен көрәшүче, бу тармакта уңышларга ирешүче стахановчыларга материаль яктан өстенлек күрсәтелергә тиеш.

Татарстанның җинел промышленность наркоматының быел ягулыкка экономия ясау өчен төзегән планы, һич шиксез, яхшы адым, җидди чара булып тора. Пар казаннары хуҗалыгын яхшырту, предприятиеләрдәге калдыклардан (Ленин исемендәге заводта каеры калдыкларын) файдалану, дизель машиналарын мазутка күчерү („Кызыл тукучы“), цехлардан артып калган парны яңадан файдалану чаралары Наркоматка быел 1 миллион сумнан артык экономия бирәчәкләр. Бу план бик реаль план. Ягулыкка һәм электроэнергиягә экономия ясау өчен Наркомместпром да, Наркомпищепром да һәм Союзный наркоматларга караган башка предприятиеләр дә шундый конкрет чаралар билгеләргә һәм аларны үтәүгә большевикларча көрәшергә тиешләр.

Ягулыкны һәм электроэнергияне саклык белән тоту, ул—кыш көннәрендә һәрбер предприятие өчен нормаль эш шартлары тудыру, производствоны тоткарсыз эшләтү дигән сүз. Ягулыкны яки энергияне лимитта каралганнан артык тоту башка предприятиеләргә зарар китерә икәнлеген истән чыгарырга ярамый. Ягулыкны экономия белән тоту аеруча әһәмиятле чара. Бер генә килограмм ягулыкны да артык тотмаска дигән лозунг тулысынча тормышка ашырылсын өчен, аны үтәүгә киң катлау массаны тупларга кирәк. Массаны социалистик милеккә коммунистик мөнәсәбәттә булу рухында тәрбияләргә кирәк.

Барлык хуҗалыкчылар ягулыкка экономия ясау өчен көрәшне большевикларча оештырырга һәм ягулык балансының төгәл үтәлүенә нык контроль ясарга тиешләр. Предприятиеләрне һәм шәһәр халкын электроэнергия белән тоткарсыз тәэмин итү өчен һәрбер потребитель энергияне куелган нормадан артык тотмаска, лимиттан читкә чыкмаска тиеш. Ягулык һәм энергия тотуда дәүләт дисциплинасы һичбер кем тарафыннан бозылмаска тиеш.

ОЗАК КӨТЕЛГӘН ОЧРАШУ ЯКЫНЛАША

МУРМАНСКИЙ, 27 гыйнвар. (ТАСС). Шәһәр бәйрәмчә бизәлде. Ул бик хаклы рәвештә Арктикага чыга торган капка дип йөртелә. Мурманский шәһәре котып иркенлекләрен батыр рәвештә буйсындыручыларны тирән мәхәббәт белән инде берничә тапкыр озатты һәм каршылады. Йортларның урам якларында, магазиннарның витриналарында иптәш Сталинның, партия һәм хөкүмәт җитәкчеләренең портретлары, легендар „Георгий Седов“ бозваткычының капитаны К. С. Бадигинның, аның батыр 14 юлдашының, Советлар Союзы Герое И. Д. Папанинның портретлары куелган. Һәр җирдә ал флаглар җилферди. Шәһәрнең иң зур бинасы булган Арктика пароходчылыгы бинасына гаять зур панно куелган. Бу панно Советның ике бозваткычының бозлар арасында тәэсирле очрашуын гәүдәләндерә.

Мурманский халкы седовчыларны елы рәвештә каршы алуга хәзерләнә.

Сәүдә портының бик күп эшчеләре седовчылар исемендәге вахтага бастылар. Мурманский һәм Кандалакша станцияләренең деполарында паровоз бригадалары геройларны Москвага алып барачак махсус поездны алып бару хокукын алу өчен ярышалар.

Җирле Советларга депутатлыкка седовчылар тавышка куелган элекке сайлау участкыларында агитаторлар хезмәт ияләренә батыр экипажның каһәрманлыклары турында сөйлиләр.

Легендар хәрәкәткә багышлап культура йортында күргәзмә ачылды. ВКП(б) Шәһәр Комитетының партия кабинетында, китапханәнең уку залында һәм судноларга ремонт ясау заводы клубында да шундый ук күргәзмәләр оештырылды.

Илнең барлык почмакларыннан седовчылар исеменә күп санда котлаулар килә. Хәрәкәттәге Кызыл Армия частьләреннән берсенең сугышчылары һәм командирлары болай язалар:

„Кадерле иптәшләр, сез үзегездә совет халкының иң яхшы сыйфатларын: геройлыкны, батырлыкны, Ватанга карата чиксез мәхәббәтне, иптәш Сталинның теләсә нинди заданиесен үтәргә хәзер торуны гәүдәләндердегез.

Сезнең героик эшләрегез безне, Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе сугышчыларын, чәчәк атучы илебез өчен, бөек Сталин өчен яңа батырлыклар күрсәтүгә рухландыралар“.

Радио станцияләре „Г. Седов“ бозваткычы бортыннан шәһәр һәм өлкә хезмәт ияләренә данлыклы экипажның котлауларын алалар. Седовчыларның соңгы радиограммасы Кола ярым атавы яшьләренә адресланган. Радиограммада түбәндәгечә әйтелә:

„Кадерле иптәшләр, елы рәвештә котлавыгыз өчен „Г. Седов“ ның бөтен экипажыннан рәхмәт. Мурманский өлкәсенең комсомолецларына һәм барлык яшьләренә туганнарча сәлам җибәрәбез. Тиздән һәм шатлыклы күрешүгә кадәр. К. Бадигин, Д. Трофимов“.

Озак көтелгән очрашу инде якын.

Н. Петров.

Арча районы, „Алан“ колхозы стахановчылары, 1940 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә кандидат булып торучы Әминә Хәйруллина (сулда) һәм Гөлсем Җәмалиева иптәшләр.

А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгы алдыннан

КЫЗЫЛ АРМИЯ ҮЗӘК ЙОРТЫНДА

Кызыл Армиянең М. В. Фрунзе исемендәге Үзәк Йорты Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына эшлекле хәзерлек алып бара. 4 нче февральдә бирегә Москва гарнизоны частьләренең хәрби хәбәрчеләре җыелачак. Аларга Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгы уңае белән Кызыл Армия матбугатының бурычлары турында доклад ясалачак. Москва гарнизоны частьләренең агитаторлары һәм пропагандистлары өчен:“ Ленин, Сталин һәм Кызыл Армия“, „Кызыл Армия төзелешенең төп этаплары“ һәм башка темаларга инструктив докладлар оештырыла. „Кызыл Армия һәм Хәрби Диңгез Флоты кешеләре художество әдәбиятында“ дигән темага лекция үткәреләчәк.

Үзәк йортның залларында совет фотография сәнгате мастерлары әсәрләреннән зур күргәзмә ачыла. Бу күргәзмә Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының тормышын һәм көнкүрешен, хәрби һәм политик хәзерлеген гәүдәләндерәчәк. Үзәк йортның китапханәсе, XXII еллыкка багышлап, әдәбият күргәзмәсе оештыра.

Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең Үзәк Музее үзенең „Регуляр Кызыл Армияне төзү“ һәм „1921—22 нче елларда Карелиядә ак фин бандаларын бетерү“ дигән бүлекләренә яңа материаллар өсти һәм „Ак финнәргә каршы сугышларның геройлары“ дигән темага күргәзмә оештыра. Москва гарнизоны частьләренә музейнең „Социалистик ватан өчен сугышларда Кызыл Армия“ дигән темага күчмә күргәзмәләре җибәрелә. (ТАСС).

ТАТАРСТАН АССР НЫҢ XX ЕЛЛЫГЫ АЛДЫННАН

МАССАНЫҢ АКТИВЛЫГЫ

Безнең районда Татарстан республикасының XX еллыгына хәзерлек башланды. Колхозчылар, эшчеләр һәм авыл интеллигенциясе бу көнне яңа казанышлар белән истә калдырырга омтылалар. Колхозчылар, ефремовчылар тәҗрибәсен кулланып, үзләренең алларына быел һәр гектардан йөз пот уңыш алу бурычын куйдылар. Чәчүгә хәзерлек киң күләмдә җәелде. Чәчүгә хәзерлекне 10 нчы февральгә тәмам итәргә карар бирелде.

Шуның өстенә колхозчылар Зур Ферганә каналын төзүчеләрнең тәҗрибәсеннән файдаланып, юлларны төзекләндерүгә бик теләп керештеләр.

Арча хезмәт ияләренең культура-көнкүреш сораулары бик нык үсә. Бу сорауларны канәгатьләндерү өчен башкарма комитет юбилей көненә водопровод төзелешен тәмам итәргә, 56 койкалы яңа больница салырга карар бирде. Барлык авылларда хезмәт ияләрен яңа алфавитка өйрәтү эше бара. Бу эшне дә орденлы Татарстанның XX еллыгына тәмам итәргә карар бирелде.

Башкарма комитет үткәрә торган чаралар арасында җирле промышленностьне үстерүгә зур урын бирелә. 2—3 айдан районда чүлмәк заводы эшли башлаячак.

К. Шәмсеттинев.
Арча райсоветының башкарма комитеты председателе.

Культура-көнкүреш учреждениеләре төзелеше

ТАССР ның XX еллыгы көне безнең районда күп кенә культура - көнкүреш учреждениеләре төзелешенең тәмам булуы белән истә калдырылачак. Иске Суксу һәм Исак авылларында мәктәпләрне төзеп бетерергә карар бирелде. Кайбер авылларда яңа уку өйләре, кызыл почмаклар ачыла. Быел районның хезмәт ияләре яңа поликлиника алачаклар. Хәзер аны эчтән җиһазландыру тәмам булып килә.

3 нче февральдә башкарма комитет клубларда, уку өйләрендә XX еллыкка хәзерлекнең ничек баруы һәм үзешчәнлек өлкәсендә нәрсәләр эшләнү турында юбилей комиссиясе председателенең докладын тыңлаячак.

И. Салахов.
Буа райсоветының башкарма комитеты председателе.

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсе ачылды

Кичә, 28 нче гыйнварда, кич сәгать 6 да Менжинский исемендәге клубның зур залы республика күләмендәге киңәшмәгә килгән алдынгылар, республика оешмаларыннан чакырылган кунаклар белән тулды. Нак сәгать 6 да, Татарстан АССР ның җир эшләре халык комиссары иптәш Черзорның киңәшмә алдында торган төп бурычлар турындагы кыскача кереш сүзеннән соң, авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсе ачылды.

Актаныш район җир бүлегенең баш агрономы иптәш Сафин Октябрь, Беренче Май, Актаныш, Норлат районнары делегатлары исеменнән киңәшмәнең президиумына 50 кеше сайларга тәкъдим итә һәм бу тәкъдим бер тавыштан кабул ителә. Президиумга көчле алкышлар астында түбәндәге иптәшләр сайланалар:

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты секретарьлары Алемасов, Матвеев, Долатказин, Гафиятуллин, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Динмөхәметов, Татарстан АССР Совнаркомы председателе Тынчеров, ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты секретаре Бычков, Совет Контроле Комиссиясенең Татарстандагы уполномоченные Рундаев, Татарстан АССР Совнаркомы председателе урынбасарлары Киселев һәм Садовников, Татарстан АССР ның җир эшләре халык комиссары Черзор, ВКП(б) Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире Саланов, ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре Перов, ВКП(б) Үзәк Комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге инструкторы Федоров, „Красная Татария“ газетасы редакторы Анушкин, „Кызыл Татарстан“ газетасы редакторы Абдрахманов, „Херле Ялав“ газетасы редакторы Скворцов, Чувашстан АССР ның җир эшләре халык комиссары Степанов, Чувашстан АССР ның Сталин исемендәге колхоз председателе Жарков, Чувашстан АССР ның Аликовский МТСы директоры Куликов, Чувашстан АССР ның Чкаловский МТС ының трактор бригадасы бригадиры Северов, Мордовия АССР ның җир эшләре халык комиссары урынбасары Яськин, Мордовия АССР ның Ленин исемендәге колхоз председателе Байчурин, Мордовия АССР Җир Эшләре Халык Комиссариатының агротехника-механизация идарәсенең баш агрономы Мельников, Мордовия АССР ның Ромадан МТС ы директоры Лапин, җир органнары работниклары Союзының Мордовия Өлкә Комитеты председателе Захаров, ВКП(б) ның Чувашстан Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире Серебрянников, Косушкин, Гаделшин, (ТАССР Наркомземы урынбасарлары), профессор Сырнев, Татарстан АССР ның Куйбышев районыннан Москвин, Актаныш район җир бүлегенең баш агрономы Сафин, Емельянова (Аксубай МТС ы) һәм Вәлиева (тракторчы), Әгерҗе районыннан колхоз председателе Нәбиуллин, Октябрь МТС ы комбайнчысы Ворухина, Ютазы районыннан Камаев, товарлыклы сөтчелек фермасы мөдире Андреева (Чистай районы), Лаеш районы колхозчысы Малинов, Малов (Буденный районы), Маскин (Дөбъяз районы), Сафин (Минзәлә МТС ы), Вәлишин (Мамадыш МТС ы), Гәрәев (Юртыш МТС ы), Дәүләтшин (Тымытык МТС ы), Абләмов (Мамадыш МТС ы), Столбище МТС ының элекке директоры орденлы Гусев.

Көчле кул чабулар астында почетлы президиумга бик зур күтәренкелек белән Сталин, Молотов, Ворошилов, Калинин, Каганович, Андреев, Микоян, Жданов, Хрущев, Берия, Шверник, Маленков, Димитров, Тельман иптәшләр сайландылар. Аннары киңәшмәнең түбәндәге көн тәртибе расланды: 1) 1939 нчы авыл хуҗалыгы елының йомгаклары һәм 1940 нчы елгы бурычлар, 2) Татарстан, Чувашстан, Мордовия республикалары арасында төзелгән социалистик ярыш договорын тикшерү һәм кабул итү.

Киңәшмәнең регламентын раслаганнан соң, көн тәртибенең беренче мәсьәләсе—1939 нчы авыл хуҗалыгы елының йомгаклары һәм 1940 нчы елгы бурычлар турында ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Матвеев гаять зур эчтәлекле доклад белән чыкты.

Киңәшмәдә Татарстан АССР ның авыл хуҗалыгы алдынгыларыннан 516 делегат, Чувашстан һәм Мордовия республикаларыннан 10 иптәш һәм 300 дән артык кунак катнаша.

Киңәшмәнең бүгенге утырышы шул ук клубта иртә белән сәгать 10 да башлана.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

27 нче гыйнварда фронтта разведчикларның эзләнүләре булды. Безнең авиация разведка очышлары үткәрде.

МТС һәм МТМ алдынгыларының РЕСПУБЛИКА ПОЧЕТ ТАКТАСЫ

ВКП(б) райкомнарының һәм хезмәт ияләре депутатлары район советларының башкарма комитетлары күрсәтүе буенча тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауда яхшы күрсәткечләр биргән алдынгылар һәм стахановчылар Республика Почет Тактасына кертеләләр:

17. Тымытык районы, Чалпы МТС ының 1939 нчы елның 24 нче декабренә үз тракторларына һәм тагылма инвентарьларга ремонт ясауны төгәлләгән тракторчылары **Р. Хәсәнева** һәм **И. Ваһапов** иптәшләр.

18. Әлки районы, Салман МТС ының эш нормасын һәр көнне 165—200 процентка үтәп баручы эшчеләре—тимерче **З. Гафиятуллин** һәм токарь **Заһидуллин** иптәшләр.

19. Әлки районы, Базарлы Матак МТС ының 1939 нчы елның 15 нче декабренә үз тракторларына ремонт ясауны төгәлләгән тракторчылары **И. Хафизов** һәм **Н. Гатауллин** иптәшләр.

20. Аксубай районы, Аксубай МТС ының 1939 нчы елның 16 нчы декабренә үз тракторларына ремонт ясауны төгәлләгән тракторчылары **Г. Миронов** һәм **В. Аквильянов** иптәшләр.

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсенә карата

ГЕКТАРЫННАН ЙӨЗ ПОТ ИГЕН УҢЫШЫ АЛЫРБЫЗ

Эшне вактында һәм җиренә җиткереп эшләргә кирәк

Безнең бишенче бригаданың участкысы Җекәнле буе дип йөртелә торган урында. Элек бу урыннан юнле иген уңышы алганны мин хәтерләмим. Җирне җан башыннан өләшеп чәчкән елларны шобагасы бу тирәгә чыккан кеше үзен бәхетсез саный, сукрана иде.

1937 нче елда шушы участкыда 23 гектар мәйданны яхшы итеп хәзерләнгән тирес белән нык кына ашладык. Шушы участкыда 1938 нче елда һәр гектардан 21 центнер бодай уңышы, 1939 нчы елда һәр гектардан 16 центнер солы уңышы чыкты.

Кыр эшләрен вактында яхшы сыйфатлы итеп үткәрү, югалтуларга юл куймау югары иген уңышы алуда гаять зур әһәмиятле урын тота. Эшнең бу моменты хезмәтне дөрес оештыруга һәм колхозчылар арасында хезмәт дисциплинасының нык булуына бәйләнгән. Без бригадада эшнең бу ягына аеруча әһәмият бирәбез.

Безнең бригадада хезмәт көннәре минимумын тутырмаган бер генә колхозчы да юк. Колхозчыларны производствода актив катнаштыру өчен һәр кемнең көченә һәм аның үз теләгенә карап эш бирә белергә кирәк. Бригадир яки звеновод өчен бу бик әһәмиятле нәрсә. Безнең бригадада яш балалы булу һәм башка сәбәпләр аркасында йорт тирәсеннән читтәге эшләргә катнаша алмаучы 7 хатын-кыз бар. Бу иптәшләргә мин бригадага кирәкле тараларны хәзерләү өчен кайсына сүс талку, кайсына җеп эрләү, кайсына киндер сугу кебек эшләр тапшырдым.

Хезмәтне шулай оештыру һәм һәрбер эшкә алдан яхшы итеп хәзерләнү нәтиҗәсендә, без бригадада барлык кыр эшләрен бик кыска срокта, яхшы сыйфатлы итеп башкарып киләбез. Югары иген уңышы алуда моның никадәр әһәмиятле урын тотуын колхозның аерым бригадалары эшендә ачык күрергә була. Безнең бригада участкысы дүртенче һәм алтынчы бригадаларның участкылары белән янәшә; туфракта артык аерма юк. Шулай ук эшләү шартлары да бер үк төсле. Шулай да безнең бригада дүртенче һәм алтынчы бригадаларга караганда уңышны ел саен күбрәк алып килә. Мәсәлән, 1939 нчы елда безнең бригада бөртекле культуралар уңышын алтынчы бригадага караганда һәр гектардан 2,37 центнер, 4 нче бригадага караганда 1,46 центнер артык алды. Бу бригадаларның уңышны ким алуларының сәбәбе, эшне соңга калып үтәүдә, эшнең сыйфат ягына әһәмият биреп җиткермәүдә, югалтуларга юл куюда.

Югары иген уңышы өчен көрәштә эшнең бөтен нечкәлекләренә җидди игтибар бирергә кирәк. Агротехника чараларын дөрес тормышка ашыру белән бергә һәр эшне вактында, җиренә җиткереп эшләгәндә, бездә һәр гектардан 100 пот һәм аннан да артык иген уңышын алырга була. Без шуның өчен көрәшәбез.

Сафа Гарипов.

Азнакай районы, „Кызыл Байрак" колхозының 5 нче бригада бригадиры

УҢЫШ ЯУЛАП АЛЫНА УЛ

Безнең Сәпәй авыл советына 3 колхоз керә: Сәпәй авылы, „Кызыл Байрак" колхозы, Мараклыбаш авылы, „Җитез" колхозы һәм „Зирекле Елга" колхозы.

Бу колхозларның өчесе дә бөртекле культураларның һәр гектарыннан быел йөз пот иген уңышы алуга ирешү өчен социалистик ярышка кушылдылар.

Гектарыннан йөз пот иген уңышы алуга ирешү мәсьәләсенә кайберәүләр бик җиңел карыйлар. Бездә моның өчен бөтен мөмкинлекләр бар, диләр. Әлбәттә бар, моны һич кем инкар итми һәм инкар итә дә алмый. Бездә гектарыннан йөз пот кына түгел, 150 пот, 200 пот һәм аннан да артыграк иген уңышы алу өчен партиябез һәм хөкүмәтебез тарафыннан барлык мөмкинлекләр тудырылган. Төп эш әнә шул мөмкинлекләрдән яхшылап, большевикларча файдалануга кайтып кала. Бөек остазыбыз иптәш Сталин, уңышларның бер вакытта да үзлегеннән килмәүләрен, ә аларны яулап алырга кирәклеген безгә әйтеп һәм күрсәтеп килә.

„Кызыл Байрак" колхозында кырчылык буенча 8 бригада бар. Беренче бригада бригадиры иптәш Мөхәммәдиев бөртекле культураларның һәр гектарыннан 8 нче бригада бригадиры иптәш Динмөхәмметовтан 40 процент чамасы артыграк алды. Монда тагын шунсы характерлы, иптәш Мөхәммәдиев бригадасына беркетелгән җирләр иптәш Динмөхәмметов бригадасы җирләреннән күп начар. Җирләре начар булуга да карамастан, иптәш Мөхәммәдиевнең уңышны Динмөхәмметовтан күп артык алуының сәбәбе агрономия чараларын дөрес үткәрүдә, һәр эшне вактында эшләүдә, югалтуларга каршы нык көрәшүдә.

Гектарыннан йөз пот иген уңышы алуга ирешү өчен башланган хәрәкәткә җитәкчелек итүдә авыл советы председательләре өстенә гаять җаваплы бурыч йөкләнгән.

Мин хәзер авыл советы председателе буларак, төп игтибарны язгы чәчүгә хәзерлек эшенә бирәм. Безнең өч колхозда да чәчү орлыклары җитәрлек. Тик кайбер культураларны үзара алмашасы бар. Колхоз председательләре белән киңәшеп мин бу эшне оештырдым инде. Авыл хуҗалыгы машиналарына һәм инвентарьларына ремонт тәгәлләнеп килә. Мин авыл советы председателе булганга кадәр „Зирекле Елга" колхозында тиресне ел саен якын басуга гына түгеп барганнар. Мин хәзер колхоз җитәкчеләре белән сөйләшеп, тиресне ерак басуга чыгаруны оештырдым. „Зирекле Елга" һәм „Җитез" колхозында кар тотуның сыйфатын тикшердем. Кар быел яхшы ятты. Җыелган карны җил алып китмәсен өчен мин бу колхозларда үземнең элеккеге тәҗрибәмнән чыгып, карны өстән чыбыклар белән тырмап бастырып чыгарга киңәш бирдем һәм алар моны эшләделәр.

„Кызыл Байрак" колхозында моннан бер ай чамасы элек атларның хәле мактарлык түгел иде. Без бу колхозда атларның язгы чәчүгә хәзерлекләрен, аларны тәрбия итү эшен даими рәвештә тикшереп тору өчен активлардан махсус комиссия төзедек. Комиссия члennарыннан ике кеше һәр көнне бер тапкыр (күбесенчә төнлә белән) ат абзарына кереп атларның хәлен тикшереп чыгалар. Кимчелекләр булса шунда ук хәл ителәләр һәм комиссия җитәкчесенә бу турыда хәбәр итәләр. Бу чара уңышлы нәтиҗә бирде. „Кызыл байрак" колхозының атлары хәзер шактый яхшырды. Яхшы ат караучыларны бүләкләү өчен колхоз правлениесе авыл советының киңәше буенча махсус фонд оештырды.

Гомумән, мин авыл советы председателе буларак, югарыда күрсәтелгән өч колхозның өчесендә дә язгы чәчүнең тулы хәзерлек белән каршы алынуына һәм большевистик оешканлык белән үткәрелүенә һәм, ниһаять, йөз пот иген уңышы алуның тәэмин ителүенә тулысынча ышанам.

Хуҗа Минһаҗев.

Азнакай районы, Сәпәй авыл советы председателе.

Йөзпотчылар хәрәкәтенә җитәкчелекне тәэмин итик

Быел илебездә югары иген уңышы алу өчен яңа хәрәкәт—йөзпотчылар хәрәкәте башланды. Бу хәрәкәт сталинчыл 8 миллиард пот ашлык җитештерүгә ирешү юлында гүзәл башлангыч. Бу бөек хәрәкәткә Энгельс исемендәге колхоз да кушылды.

Бу данлыклы хәрәкәткә җитәкчелек итү—партия оешмаларының мактаулы эше булып тора.

Без, Калинин районы авыл хуҗалыгы алдынгылары мөрәҗәгатен партоешманың актив белән катнаш җыелышында тикшердек. Мөрәҗәгатне барлык колхозчыларга җиткерү өчен активистлардан һәр бригадага аерым иптәшләрне беркеттек. Бу мөрәҗәгат барлык бригадаларда, барлык колхозчыларның катнашы белән тикшерелде һәм яхшы дип табылды. Энгельс исемендәге колхоз членнары бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 100 пот иген уңышы алу өчен үз өсләренә йөкләмә алдылар һәм районыбызның „Кичү" колхозы членнарын социалистик ярышка чакырдылар. Бригадалар арасында һәм „Кичү" колхозы белән безнең колхоз арасында төзелгән ярышның үтәлешен системалы тикшереп бару өчен комиссияләр оештырдык.

Бригадаларда масса-аңлату эшләре алып бару өчен партоешма коммунистлардан, комсомоллардан һәм партиясез активистлардан аерым иптәшләрне беркетте. Алар бригадаларда масса эшләре алып бару белән бергә, производство планының төгәл үтәлүенә контрольлек тә алып баралар. Ике урында агротехника укулары оештырылды, анда 40 кеше укый. Югары иген уңышы алу өчен агротехника чараларын вакытында, яхшы сыйфат белән үтәгән бригадаларны бүләкләү өчен колхоз правлениесе бүләкләү фонды билгеләде.

Йөзпотчылар хәрәкәтенең әһәмиятен җентекләп аңлату нәтиҗәсендә, колхоз членнары бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача йөз пот уңыш алуга зур ышанганлыкларын белдергән хәлдә, бу теләккә ирешү өчен киң көрәш башладылар.

Чәчү орлыклары тазартылып, район лабораториясе аркылы анализдан уздырылды. 1.033 гектар мәйданда кар тотылды (план 800 гектар иде), басуга кышкы план исәбенә 2.646 йөк тирес чыгарылды. Фекали, кош тизәге һәм көл җыю эшләре дә уңышлы бара.

Тырмаларга һәм чәчү машиналарына ремонт эшләре тәгәлләнде, сабаннарга ремонт эшләре тәгәлләнү алдында. Сбруйлар тулысы белән хәзерләнеп куелды.

Язгы кар суларын күбрәк тотып калу, игеннәрне тукландыру өчен хәзерлек алып барабыз.

М. Мостафин.

Азнакай районы, Энгельс исемендәге колхозның парторгы.



Азнакай районы алдынгылары (сулдан уңга): язгы чәчүгә яхшы хәзерләнүе өчен кызыл байрак белән бүләкләнгән „Яңа Көч" колхозының председателе Ш. Хәлимев, Сәпәй авылы, „Кызыл Байрак" колхозы бригадиры С. Гарипов, „Герой Труда" колхозы фермалары мөдире Е. Д. Максименко иптәшләр. Алар өчесе дә авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсе делегатлары.

И. Галиев фотосы.

ТУЛЫ ЫШАНЫЧ БЕЛӘН

Безнең колхозыбыз 1937—1938 нче елда бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 14,51 центнер иген уңышы алып, үткән елны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашты. Күргәзмәдә катнашу безгә иген уңышын күтәрү, терлекчелекне үстерү буенча чиксез күп мөмкинлекләр барлыгын күрсәтте. Хәзергә кадәр план буенча бирелеп килә торган агрономия чараларын тулысынча һәм дөрес итеп үткәргәндә иген уңышын бик тиз күтәрергә мөмкин икәнлегенә тәмам ышандык.

Менә шуңа күрә дә без йөзпотчылар хәрәкәтенә зур теләк белән һәм бу данлыклы хәрәкәтнең алдынгысы булачагыбызга нык ышанган хәлдә кушылдык.

Без үзебез белән ярышка „Җитез" колхозын чакырып, быел бөртекле һәм кузаклы культураларның һәр гектарыннан уртача 19 центнер иген уңышы алуга ирешүне йөкләмә итеп алдык.

Бу йөкләмәне үтәү өчен без хәзер нәрсә эшлибез соң? Барыннан да элек, кышкы агрономия чараларын дөрес һәм тулысынча үткәрәбез һәм шул ук вакытта ашлама хәзерләү буенча өстәмә мөмкинлекләрдән файдалануны оештырабыз.

Үткән елны басуга тирес чыгару буенча безгә 10.200 центнер күләмендә план бирелгән булса, быел без бу планны 14 мең центнер итеп кабул иттек һәм хәзер бу планны үтәү өчен барлык чараларны күрәбез. Кар тоту планын арттырып үтәдек: план 70 гектар иде, 180 гектарда тоттык. Кош тизәге хәзерләү буенча Бөгелмә кошчылык комбинаты белән, көл хәзерләү буенча „Спартак" артеле (агачтан әйбер эшләү артеле) белән договор төзедек. Язгы кар суларын тоту буенча безгә план бирелмәсә дә, без быел бу чараны да үткәрергә карар бирдек. Безнең солы орлыгында овсюг (кыргый солы) бар. Без бу куркынычлы чүпне быел бөтенләй бетерергә булдык. Моның өчен солыны триер аркылы үткәрәбез. Триердан соң да овсюг калса аны кул белән чүплибез. Бодайның бөтенесен дә тик яровойлаштырып кына чәчәргә планлаштырабыз. Җирләре безнең бөтенесе дә тирән итеп һәм вактында тунга сөрелгән. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау яхшы бара. Атларыбызның да торышы канәгатьләнерлек. Кадрлар да җитәрлек. Мәсәлән, сөрүдә 1,5 гектарлык норманы 2 гектарга кадәр үтәүче иптәш Фәттахов кебек стахановчыларыбыз шактый күп.

Елына 8 миллиард пот ашлык җитештерүгә ирешү турында иптәш Сталин тарафыннан бирелгән заданиене тизрәк үтәүдә йөзпотчылар хәрәкәте һич шиксез көчле этәргеч булачак.

Яшәсен йөзпотчылар хәрәкәте! Барыбыз да аңа кушылыйк!

Хәмзә Шаһиев.

Азнакай районы, „Зирекле Елга" колхозы председателе.

ЯҢА КӨЧ

Кич аяз. Йолдызлар ачык җемелдәп яналар. Тулган ай яктысында карның кристаллы парчалары энҗе бөртекләредәй ялтырыйлар. Һәр як тын. Туры айгырның сирәк-сирәк кенә баш чайкап, пошкырып алуы, чана табаннарының ярмаланган кар өстендә ыңгырашып шуулары гына тынлыкны бераз боза.

Кайбер кешеләр кышны ямьсез диләр. Бер дә алай түгел. Кышның мондый кичләрендә юлда баруның үзенчә бер тәмлелеге һәм күңеллелеге бар. Колак яфракларын чеметкәләп ала торган салкында да кичнең бу матурлыгы җанга җылылык бирә. Кичнең матур тынлыгын бозарга теләмәгәнгәме, яки күңелдәге тәмле уйларны өзәсе килмәгәнгәме, без, юлчылар, барыбыз да тын барабыз. Ат тоткан Мөстәкыйм абзый да безнең каршыга килүче юлчыларга юл биргәндә дәшмитынмый гына атка дилбегә кага. Тигез җирләрдә дә атның корсак астына җитә торган карның башкаларга юл биргәндә уңайсызлавына ул бер дә борчылмый.

Шәһәрдән чыккач 25—30 километрлар килгәнбездер. Без барасы район үзәге Азнакайга тагын 15 километр чамасы юл бар. Без шулай һәр кайсыбыз үз алдына уйланып озак кына тын барганнан соң, Мөстәкыйм абзый үз колхозы турында безгә нәрсәдер бер яңа хәбәр сөйләргә теләгәндәй итеп:

— Әнә шул сыртны үткәч тә безнең „Яңа Көч" колхозы инде,—дип алга күрсәтте. Без дә аның сүзенә кушылып, колхозларында эшләрнең ничек баруы турында сораштырырга керештек.

— Хәзер эш яхшы бара инде,—ди ул.

— Нигә, әллә элек начар бара идеме,—дип сорау бирәбез.

— Начар бара иде шул,—ди.

— Председателегез кем?

— Хәлимев дигән егет. Яңарак кына сайлап куйдык әле. Уңган кеше булып чыгар, ахры,—ди Мөстәкыйм абзый. Һәм шунда ук сүзен дәвам иттереп:

— Туган, без бу соңгы ике ел эчендә 6—7 председательгә җиттек. Уңмадык. Кайсы эшли белмәде, кайсысы үзе эшләргә теләмәде. Шулай булгач, эштә таркаулык туды. Шуның аркасында бу соңгы елларда безнең колхоз начар эшләве белән районда һәр вакытта мисалгә алына торган колхоз булды. Менә бу председателебезне сайлаганга өч айдан артык юктыр әле. Колхозда эшләр гел көйләнеп китте. Колхозчылар да дәртләнеп эшли башладылар. Язгы чәчүгә хәзерлек буенча районда алдынгылыкны алдык. Районнан күчмә кызыл байракны безнең колхозга тапшырдылар,—дип, колхоз председателенең дә, колхозчыларның да яхшы эшләүләре белән мактанып алды. Үзе тагын туры айгырның дилбегәсен тартып җибәрде.

Ул арада безнең алда „Яңа Көч" колхозының утлары да күренде. Без турыдан-туры бу колхозга килергә дип юлга чыкмасак та, яңа председательнең эше белән танышасыбыз килгәнгә һәм Мөстәкыйм абзыйның да үз колхозларын бик күрсәтәсе килгәнгә „Яңа Көч" колхозына тукталырга булдык.

Безне аеруча кызыксындырган нәрсә яңа председатель Шиһап иптәш Хәлимевнең аз гына вакыт эчендә колхозчылар арасында үзен эшлекле председатель итеп танытуы һәм бу колхозның районда алдынгылыкны яулап алуының сәбәпләре белән танышу иде. Исәнлек-саулык сорашкач та, безнең аңа беренче сорау „Яңа Көч" колхозының моңа кадәр ни өчен артка калып баруы турында булды. Ул безнең бу соравыбызга алдан җавабын хәзерләп куйгандай:

— Эшне оештыра белмәүдә, хезмәт дисциплинасының таркалуында гына, башка бер нәрсә дә юк. Иген уңышы да, башкасы да шуңар бәйләнгән инде аның,—дип җавап кайтарды. Һәм ул бу җавабын исбат итү өчен моңа кадәр үзе берничә ел рәттән председатель булып эшләгән Киров исемендәге колхоз тормышыннан һәм „Яңа Көч" колхозыннан чагыштырма рәвештә күп кенә мисаллар китерде. Бу мисаллар чыннан да төпле һәм эшлекле мисаллар иде.

Киров исемендәге колхоз басуында таулы - ташлы урыннар күп, туфрагының да күпчелеге комсу. Ә „Яңа Көч" колхозының басуы тигез дә һәм туфрагы да яхшы, кара туфрак. Шулай да бу ике колхозның уңыш алуында күп кенә аерма бар. Үткән елны Киров исемендәге колхоз бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 6 центнер иген уңышы алган. Иптәш Җәббаров бригадасында 50 гектар солының һәр гектарыннан уртача 11 центнер, иптәш Хөснуллин бригадасында 80 гектар бодайның һәр гектарыннан 8 әр центнер уңыш чыккан. Билгеле, бу зур уңыш түгел, шулай да „Яңа Көч" колхозында алынган уңышка чагыштырып караганда аерма зур. Чөнки бер үк төрле һава шартларында „Яңа Көч" колхозында үткән ел бөртекле культуралар уңышы һәр гектарга бары 2,75 центнер туры килә.

Киров исемендәге колхоз членнары 1937 нче елда һәр хезмәт көненә уртача 12 шәр килограмм бөртекле ашлык булгәндә, „Яңа Көч" колхозы членнары 7 шәр килограмм гына булгәннәр. Ике колхоз членнарының доходларындагы бу аерма соңгы ике елда да шулай шактый зур.

„Яңа Көч" колхозында яхшы туфрактан начар уңыш алуның, хезмәт көннәренә аз продукт булүнең сәбәпләрен эзләп ерак китәсе юк. Моны иптәш Хәлимев тә, колхозчылар үзләре дә әйтеп торалар. Бу колхозда агротехника чаралары планы бер вакытта да тулысынча үтәлмәгән, эшнең сыйфаты начар булган. Үткән ел кар тоту планы бары 54 процент, кар сулары тоту планы 30 процент, басуга тирес чыгару планы 30 процент, кош тизәге җыю планы 13 процент кына үтәлгән. Компост ашлама хәзерләү, игеннәрне тукландыру, мульчировать итү кебек эшләр турында уйлап та караучы булмаган. Игеннәрне тәрбияләүгә бөтенләй игтибар бирелмәгән. Кыр эшләре соңга калып башкарылган. Башка колхозлар чәчүгә чыкканда „Яңа Көч" колхозында орлык хәзерләп, машиналарга ремонт ясап вакыт уздыру, көзге яңгырларда көлтә ташып кибән кую, ашлыкны чертү кебек хәлләр гади нәрсә булып киткән. Үткән ел җыелмаган 8 гектар җитен дә хәзер тирән кар астында калган инде.

„Яңа Көч" колхозының моңа кадәр начар эшләве белән мисалгә алынуына, иген уңышының түбән булуына, колхозчыларның аз доход булүләренә төп сәбәпләр әнә шулар.

„Яңа Көч"тә яңа председатель сайлангач, колхозчылар бу сәбәпләрне өйрәнгәннәр. Бу җитешсезлекләрне бетерү, яңача эшләү, колхозны оешу - хуҗалык ягыннан ныгыту, мул иген уңышын яулап алу өчен практик чаралар билгеләгәннәр. Хәзер колхозда шуның өчен нык көрәш бара.

Колхозчылар йөзпотчылар хәрәкәтенә кушылып, быел бодайның һәр гектарыннан 17 центнер, солының һәр гектарыннан 18 центнер һәм башка культуралар буенча да югары уңыш алу турында конкрет йөкләмәләр алганнар. Үткән ел гектарыннан бары 30—35 пот уңыш алып та, быел һәр гектардан кимендә 100 пот уңыш алу бурычын кую зур сикереш. Ләкин колхозчыларның бу зур уңышны яулап алуга ышанычлары зур һәм нигезләре дә төпле.

Колхозда кар тоту планы арттырып үтәлгән. Тирес чыгару планы 65 процент, көл җыю планы 110 процент, кош тизәге җыйнау планы 80 процент үтәлгән инде. Машиналарга яхшы сыйфатлы итеп ремонт ясалган. Чәчү орлыклары хәзерләнеп куелган һәм алар яхшы урыннарда сакланалар. Колхозчылар өчен агротехника укулары оештырылган һәм укуларга 62 колхозчы тартылган, шушы көннәрдә стахановчылар мәктәбе эшкә башлый.

— Бу чаралар югары иген уңышы алу өчен көрәшнең башлангычы гына әле. Ныклы көрәш алда. Язгы чәчүне агротехника кагыйдәләренә төгәл туры китереп үткәрү, игеннәрне тәрбияләү һәм һичбер югалтусыз җыеп алу кебек зур әһәмиятле эшләр тора. Без боларның барсын да уңышлы үткәрү өчен хәзерләнәбез һәм һәрберсен төгәл үтәрбез. Югары уңышны яулап алырбыз,—ди „Яңа Көч"нең яңа председателе иптәш Хәлимев.

А. Вәлеев.
А. Байбеков.

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсенә карата

СОЦИАЛИСТИК АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫН ТАГЫН ДА КҮТӘРҮ ӨЧЕН БАРЛЫК МӨМКИНЛЕКЛӘРДӘН ФАЙДАЛАНЫРГА

ДАИМИ ЗВЕНОЛАР

Куйбышев районының колхозларында һәм совхозларында үткән язны кырчылык бригадаларында 300 гә якын даими звенолар оештырылган иде. Алар үзләрен тулысынча акладылар. Мондый звенолар эшләгән колхозларда бөртекле ашлыкларның уңышы ике-өч тапкыр югары булды.

Үткән ел Татарстанның Куйбышев районындагы корылыкны 1921 нче елны булган корылык белән генә чагыштырып була. Әгәр дә 1921 нче елны 10 ай эчендә явым-төшем 134,9 миллиметр булса, ул 1939 нчы елны 10 ай эчендә 133,9 миллиметр гына булды.

Ә иген уңышы? 1921 нче елда гектарына 0,3 центнер, 1939 нчы елны исә — гектардан уртача 4,2 центнер булды, ягни 1.400 проценттан артык! Бу факт бер үзе генә дә колхоз строеның һәм машина техникасының корылыкка каршы көрәштә дә гаҗәп зур көч булуын күрсәтә.

Даими звеноларның уңышлы эшләренең матур тәҗрибәләрен күрү өчен „Красный Пахарь“ колхозын алып карыйк. Үткән ел районда иген уңышы уртача 2,4 центнер булганда, бу колхозның даими звенолары гектардан 5 әр центнер уңыш алдылар. Яз чәчкән бодайның уңышы гектардан 9,6 центнер ә район күләмендә — 5,5 центнер булды. Бу колхозның күршесе — М. Горький исемендәге колхоз исә 2,8 центнер алды.

„Красный Пахарь“ колхозы звенолары бу уңышка пар басуларын яхшы хәзерләү, тунга сөрүне тирән үткәрү, кар тоту нәтиҗәсендә, күп дым булдыру аркасында ирешteләр.

Алар язгы чәчүне 4 көндә үткәргәннәр. Яровойлаштырылган һәм агуланган орлыклар чәчкәннәр. Звенолар чәчү беткәннән соң ук чәчүлекләрне караудa, тәрбияләүдә ярышып эшләгәннәр. Берничә тапкыр утыйлар. Комбайннар эшләү өчен, югалтулар булмасын өчен барлык шартлар тудырыла.

Елизавета иптәш Горлова звеносы ярышта беренчелекне ала. Аның участкысындагы һәр гектар 10 центнер ашлык бирә. Бу уңыш звенодагы эшне тагын да көчәйтә. Тунга сөрү планы тулысынча үтәлә. Хәзер кар тоту, ашлама җыю, аларны кырга чыгару эшләре бара; кичләрен ефремовча эш методларын өйрәнү өчен стахановчылар мәктәбендә укыйлар.

Колхозчылар йөзпотчылар ярышына да зур дәрт белән кушылдылар.

„Возрождение“ колхозындагы звенолар эшенең дә нәтиҗәләре гүзәл. Иптәш Анастасия Князева звеносы 40 гектар мәйданда һәрбер гектардан 12 центнер бодай алды. Ә бодай уңышы колхозда уртача 8 центнер булды. Колхоз басуларында тотылган кар калынлыгы 15—18 сантиметр, ә Князева звеносы участкысында 30—35 сантиметр инде. Үткән ел звено үз участкысының яртысын, гектарга 1 центнер хисабыннан, суперфосфат белән, ә калган өлешен көл һәм сыекча белән ашлаган.

Князева звеносы чәчүне 4 нче апрельдә бер көн эчендә үткәргән. Чәчүлеккә мульчирование үткәрелгән һәм ике тапкыр утаганнар. Уңышны комбайн белән, югалтусыз урып-җыйганнар.

Иптәш Князева звеносы югары уңышны коры елда да алырга мөмкин булуны ачык күрсәтте.

Декабрь аенда „Возрождение“ колхозчылары түгәрәкләрдә укый башладылар, югары уңыш алу өчен көрәш юлларын өйрәнү эшенә ныклап керештеләр.

Уку планында бөтен нәрсә каралган: колхозның туфрак, һава шартлары, хуҗалык юнәлеше. Алар түгәрәктә колхоз җирләренең туфрагын эшләү методларын, ашлау ысулларын, ефремовча эшләү юлларын өйрәнәләр. Колхоз агрономы иптәш Аношкин түгәрәктә лекцияләр укый. Куйбышев шәһәрендәге тәҗрибә кыры станциясе дә түгәрәккә зур булышлык күрсәтә. Алар колхоз җирләренең туфрагына химик анализ ясаганнар, туфракны нәрсә белән һәм ничек ашлау, ничек эшләү юлларын күрсәткәннәр. Шулай, югары уңыш өчен көрәш сукыр килеш бармый, бәлки фәнгә, тәҗрибәгә таянып эшләнә.

Колхозчылар алга зур бурычлар куялар. Алган йөкләмәләр буенча, 1940 нчы елда бөртекле ашлыклар уңышы 110 пот булырга тиеш. Бу — барлык колхозчылар өчен уртак бурыч. Иптәш Князева звеносы ефремовча участкыда гектардан 200 пот алу өчен көрәшә.

Районның „КИМ“ совхозында да даими звенолар яхшы нәтиҗә бирделәр. Чөгендер үстерү буенча эшләгән П. А. Горилова звеносы 1,8 гектар участкыдан 300 центнер чөгендер уңышы алды. Әгәр дә совхозда чөгендер уңышы уртача 64 центнер, ә трест буенча бары 40 центнер гына булуны истә тотсак, иптәш Горилова ирешкән уңышның ничаклы зур, ничаклы әһәмиятле булуы үзеннән-үзе күренеп тора.

Горилова звеносы тунга сөрүне 22 сантиметр тирәнлектә үткәргән, чөгендерне рассада белән утырткан, җәй көннәрендә берничә тапкыр су сипкән. Июнь ахрында сыекча тиресне су белән катнаш итеп чөгендер участкысына тараткаННар. Мондый сыекча бер гектарга 400 тонна киткән. Шуның өстенә 5 тонна сыекча таратылган. Җәй көне чөгендер араларын өч тапкыр сызалар, өч тапкыр утыйлар.

Шушы тәҗрибәләргә таянып, совхозда хәзер чөгендер үстерү буенча 4 звено һәм бөртекле ашлыклар буенча ефремовча 2 звено оештырылды.

Даими звенолар эше практикада әнә шулай акланды. Хәзер 11 колхозда яңадан 96 даими звено төзелде. Колхозларда 8 һәм совхозларда 2 урында стахановчылар мәктәбе эшли.

Г. Цуулин.

ВКП(б) Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге инструкторы.



Социалистик авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсенә делегат булып катнашучылардан бер төркем. Сулдан уңга — М. Әхметова (Мамадыш районы, „Оборона“ колхозы звеноводы), Г. Зайцев (Мамадыш районы, Молотов исемендәге колхозның агротехнигы), Г. Мөхәмметшин (Әгерже районы райзо мөдире) һәм С. Сәмитов (Буа МТС ы ның участкы агротехнигы) иптәшләр.

И. Галиев фотосы.

ЕЛ САЕН МУЛ УҢЫШ

Колхоз төзелеше елларына кадәр Нөнәгер авылында яшелчә үстерү эше белән бер генә хуҗалык та шөгылләнми иде. 1930 нчы елны авылда „Крестьянская Газета“ колхозы төзелгәннән соң, яшелчә үстерү эшенә керештек. 1931 нче елны колхоз правлениесе мине яшелчәчелек бригадиры итеп билгеләде. Беренче елда минем бригадага 1,7 гектарлы участкы һәм 4 колхозчы беркетелде. Яшелчә үстерүдә тәҗрибә булмаганлыктан, ул елны уңыш та канәгатьләнерлек булмады. Кәбестәнең гектарыннан 180 центнер, кыярның гектарыннан 200 центнер уңыш алдык.

1934 нче елны колхоз правлениесе безгә 15 гектарлы участкы беркетте. Яшелчәдән югары уңыш алу өчен „Кызыл Юл“ колхозының яшелчә бригадасын ярышка чакырды. Ярышып эшләү уңышлы нәтиҗә бирде. Кәбестәне гектарыннан 2.108 пот, чөгендерне — 1.920 пот, кишерне гектарыннан 2.108 пот алдык. Без шушыннан соң, никадәр яхшы эшләсәң шул кадәр яхшы уңыш алырга мөмкин икәнлеген һәм алынган уңышның чик түгеллеген үз практикабызда күргәч, тагын да зуррак дәрт белән эшли башладык. 1937 нче елда чәчеләчәк участкыларны 1936 нчы елның көзендә 20 сантиметр тирәнлегендә тунга сөреп калдырдык һәм гектарга 40 тонна исәбеннән тирес керттек. Яз көне туфрак өлгергәч участкыны тагын сөрдек һәм тырмаладык, яңадан һәр гектарны 1,2 центнер фосфор оны белән ашладык.

Яшелчә утырту тәгәлләнгәннән соң беренче өч көнгә кадәр һәр көнне ике тапкыр су сиптек. Сезонга өч тапкыр чүп утау һәм ике тапкыр яшелчәләрнең төпләрен йомшарту үткәрдек. Үсү чорында һәрбер төп яшелчәгә бер литр хисабыннан тирес сыекчасы белән тукландырдык. Яшелчәне корткычлардан саклау әһәмиятле чара. Шуңа күрә без һәр елны агач көле хәзерләп куябыз. Әгәр дә яшелчәгә борча төшсә, шул көл белән агулыйбыз.

Бригада членнары арасында хезмәт дисциплинасы яхшы. Тәҗрибәләрне уртаклашу нигезендә бригадада производство киңәшмәләре үткәрүне киң кулланабыз. Шулай итеп, 1937 нче елны безнең бригада кәбестәне һәр гектардан 2.700 пот, кыярны — 1.800 пот, кишерне — 2.400 пот һәм чөгендерне 2.800 пот алды. 1938 нче елны да шундый ук уңыш алдык. Шул уңышларыбыз белән 1939 нчы елны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнаштык. Күргәзмә Баш Комитеты безне дүртенче дәрәҗә диплом белән бүләкләде.

Үткән елны һава шартлары яхшы булмаса да, күрсәткечләребез түбән түгел. Без 1940 нчы елны да күргәзмәгә катнашу өчен кандидат булып торабыз.

Быел да югары уңыш алу өчен барлык чараларны күрәбез.

Шәфик Сафиуллин.

Чепья районы, „Крестьянская Газета“ колхозының яшелчәчелек бригадасы бригадиры.

ЯХШЫ ФЕРМА

Чистай районы, „Чаткы“ колхозының сарык асраучылык фермасы 1935 нче елда гади нәселле 27 баш сарыктан оештырылган була. Башта сарыклар өчен җылы һәм якты торак, җитәрлек азык булмый. Моның өстенә сарыкларны зоотехника-ветеринария кагыйдәләре буенча тәрбияләү өчен тәҗрибәләр дә тупланмаган була. Ферма работниклары һәм барлык колхозчылар бу мәсьәләләр турында кат-кат сөйләшкәннән соң, эшне җылы, якты торак, җитәрлек санда азык хәзерләүдән башлыйлар.

Активистларның башлап йөрүе буенча, колхозчыларның тырышлыгы белән, кыска гына вакыт эчендә җылы, якты абзар салдыралар. Аның эчендә су җылыту, азык парлау, изолятор бүлмәләре бар. Сарыкларны көндез чыгарып йөртү өчен махсус урын хәзерләнгән.

Хәзер ферманың эше яхшы. Фермада сарыкларны ашату, тәрбияләү эше зоо-ветеринария кагыйдәләре буенча алып барыла. Иртән сәгать 5 тә һәр сарыкка 1 килограмм, тәкәләргә 1.200 грамм бодай яки солы саламы бирелә. 6 сәгатьтә, 10—12 градус җылылыктагы тозлы су эчерелә. Көн яхшы булганда сарыклар саф һавага чыгарыла. Сарыклар тышта йөргәндә, аларның тораклары, ашау-эчү урыннары яхшылап тазартыла. Шуннан соң һәрбер сарыкка берәр килограмм бодай яки солы кибәге бирелә. Иртәнге 9 белән 10 сәгать арасы — бәрәннәр имезү вакты.

Көндезге сәгать 12 дә һәрбер сарыкка 1 килограмм салам, ә бәрәнле сарыкларга шуңа өстәмә итеп азык чөгендере бирелә. Төштән соң сарыкларга ял сәгате була. Кичке 4—5 арасында җылы су эчертелә һәм кичкә хәзерлек алып барыла. Төнгә бирелә торган азык, көндезге нормага караганда, күбрәк бирелә, азыкка тозлы су сибелә. Арыклана башлаган сарыклар булса, алар аерып алына һәм аларга аерым азык хәзерләнә.

Үз вактында ашату, эчертү, дөрес тәрбияләү нәтиҗәсендә, сарыкларның көрлеге арта, продуктлылыгы күтәрелгәннән-күтәрелә бара. Бәрәннәр эре, таза булып туалар, матур булып үсәләр. Монда сарыклар ел саен бәрәнлиләр һәм барлык бәрәннәр исән үсәләр. Ел саен һәрбер 100 сарыктан 133 бәрән алына (план буенча 120 бәрән). Һәрбер олы сарыктан 3 килограмм 720 грамм, нәселле тәкәләрдән 5 килограмм 320 грамм йон алына. Үткән елларда авырлыклары 35—40 килограммнан узмаган сарыклар, хәзер 50 — 55 һәм 60 килограммга кадәр артты. 33 нче номерлы сарык һәр елны 6 бәрән китерә, бу сарыкның тере үлчәве 63 килограмм. Мондый сарыклар фермада елдан-ел арта баралар.

Колхоз председателе Булатов, ферма мөдире Юлдашев иптәшләр фермага азык хәзерләүгә аеруча зур игтибар бирәләр. Азыкны алдан ук җитәрлек санда хәзерләү һәм саклап тоту нәтиҗәсендә, сарыклар һәр вакытта көр, таза булалар. 1939 нчы елда терлек азыклары хәзерләү өчен колхозда махсус бригада эшләде. Шушы бригада инициативасы буенча 130 центнер печән, 50 центнер силос, 139 центнер яфрак хәзерләнде. 8 гектар тамыр азык чәчелде.

1939 нчы елда терлек үрчетү планы 220 баш урнына 269 баш итеп үтәлде һәм 1940 нчы ел өчен ит тапшыру планының 50 проценты хәзердән үк үтәлде.

Шушы уңышларны яулап алу өчен ферма һәм аның мөдире иптәш Юлдашев 1939 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашу хокукын алды.

Бу ферма 1940 нчы елда да күргәзмәгә катнашу өчен кандидат булып тора.

Ферма өченче ел инде Тукай исемендәге колхозның сарык асраучылык фермасы белән ярыша.

Фермада эшләүче колхозчылар арасында хезмәт дисциплинасы яхшы куелган.

Ферманың доходы елдан-ел үсә. 1937 нче елда фермадан 8.050 сум доход алынган булса, 1938 нче елда 16.000 сум, ә 1939 нчы елда 19.000 сум доход алынды.

К. Исламов.

Биектау районы, Буденный исемендәге колхозның ат караучысы иптәш Е. Г. Мухоричев Привод исемле нәсел айгыры белән.

И. Галиев фотосы.

Ашламалардан тулы һәм дөрес файдаланыйк

ВКП(б) ның XVIII нче съезды авыл хуҗалыгы алдына гаять зур бурычлар куйды. Өченче бишьеллыкта без бөртекле культураларның еллык уңышын 8 миллиард потка җиткерергә тиешбез. Бу бурычны уңышлы хәл итү өчен агрономия фәненең һәм техникасының барлык яңа казанышларыннан файдаланырга кирәк.

Колхоз һәм совхоз кырларында да органик, минераль һәм бактерияле ашламаларны киң күләмдә куллану иген уңышын күтәрүдә хәл иткеч чараларның берсе булып тора.

Иптәш Молотов XVIII нче съездда ясаган докладында авыл хуҗалыгын тагын да күтәрү өчен туфракны ашлауның дөрес системасын кертү һәм, гомумән, авыл хуҗалыгын химияләштерүне үстерү кирәклеген әйтте. ВКП(б) ның XVIII нче съезды „Колхозларда һәм совхозларда органик һәм минераль ашламалар куллануның дөрес системасын үзләштерергә...“ дип күрсәтте.

Соңгы елларда безнең илебездә социалистик авыл хуҗалыгын минераль ашламалар белән тәэмин итүче көчле химия промышленносте үсте. 1933 нче елда авыл хуҗалыгы химия промышленностыннан 3 миллион тоннадан артык ашлама алды. Бу сан патша Россиясе вактындагы белән чагыштырганда 50 тапкыр артык.

Өченче бишьеллык планда ашлама җитештерү промышленносте тагын да куәтлерәк үсәчәк. 1942 нче елда илебезнен авыл хуҗалыгы 10 миллион тонна минераль ашламалар алачак.

Колхозларның һәм совхозларның берничә еллык тәҗрибәләре һәм тәҗрибә станцияләренең күрсәтүләре нигезендә, академик Прянишников минераль ашлама сыйфатында туфракка кертелгән һәрбер килограмм азот уңышны бөртекле культуралар буенча 10 килограммга, бәрәңге буенча 88 килограммга күтәрүен исәпләп чыгарган. Бу, икенче төрле әйткәндә, бер гектарга азоты 20 процент булган аммони сульфаты керткәндә бөртекле культураларның уңышы 4 центнерга, ә бәрәңгенең 35 центнерга арта дигән сүз.

Социалистик игенчелек алдынгылары тагын да югарырак уңышларга ирешәләр. Ярославль өлкәсенең „Красный Льновод“ колхозы ашламаларны системалы рәвештә куллану нәтиҗәсендә, башка колхозларга караганда 6 ел буена икеләтә артык уңыш алып килә.

Минераль ашламаларның югары эффектлылыгын күрсәткән мондый мисальләр Татарстан АССР колхозлары практикасында да аз түгел. 1937 нче елда Норлат районының „Совет“ колхозында алдагы елда азотлы ашлама кулланылган участкыда фосфорит оны кертү нәтиҗәсендә, арыш уңышы гектарына 6 центнер артык чыкты. Шул ук елны Казан селекция станциясендә ашланмаган участкыда борчак уңышы гектарына 11,3 центнер, ә фосфорит оны кертелгән участкыда — 14,8 центнер булды. Без инде яхшы нәтиҗә бирүләре белән күпләргә билгеле булган кали тозы, суперфосфат, аммиаклы селитра, аммони сульфаты кебек ашламалар турында әйтеп тә тормыйбыз.

Ләкин әле бездә хәзергә кадәр минераль ашламаларга бәя биреп җиткермәүче колхоз җитәкчеләре һәм колхозчылар бар. Бу хәл, беренче чиратта, минераль ашламаларның аерым үзенчәлекләре белән таныш булмаудан килеп чыга. Ә ашламаларның бик күп төрле үзенчәлекләре бар.

Мәсәлән, фосфорит онын алып карыйк. Ул еш кына хәлләрдә туфракка кертелгән елында ук уңышка йогынты ясамый. Сабан ашлыгы астына кертелгәндә бигрәк тә шулай. Аның нәтиҗәсе туфракка керткәннән соң берничә ел буена дәвам итә. Смоленск тәҗрибә станциясе мәгълүматларына караганда, фосфорит онының уңышка тәэсире 10 ел буена бара. Фосфорит оны көлсу туфраклар өчен иң яхшы ашлама булып исәпләнә.

Ашламаларның эффектлылыгын күтәрүдә аларны куллану сроклары һәм ысуллары хәл иткеч әһәмияткә ия булып тора. Ашламаларны бөртекле уҗым культуралары астына парга сөргәндә, бөртекле сабан культуралары һәм барлык техник культуралар астына тунга сөрү вактында кертеп калдырырга кирәк.

Фәнни учреждениеләрнең һәм алдынгы колхозларның, совхозларның тәҗрибәләрендә күренгәнчә, ашламалар туфракка тирән күмдерелгәндә яхшырак нәтиҗә бирәләр. Сөрү тирәнлегенә күмдерелгән ашлама елның иң коры вактында да туфракның дымлы катлавында була һәм, димәк, үсемлекләр өчен һәр вакыт үзләштерерлек хәлдә тора.

Органик һәм минераль ашламаларны кушып куллану аларны рациональ файдалануга нык ярдәм итә.

Иген уңышын күтәрүдә иң әһәмиятле чаралардан тагын туфракны известьләүне күрсәтергә кирәк. Туфракны ашлау буенча дөрес кулланылган система үз эченә көлсу туфраклы зоналарда тирес һәм минераль ашламалар белән бер рәттән, известьне дә алырга тиеш. Известьләү көлсу туфракларның әчелеген бетерә. Известька ярлы туфракларда тирес тә һәм минераль ашламалар да үзләренең тулы йогынтыларын ясый алмыйлар. Үләнле, аерым алганда клевер һәм люцерналы чәчү әйләнешләрендә туфракны известьләү бигрәк тә кулланылырга тиешле төп чара. Известьләгән туфракларда клевер уңышы гектарына 35 центнерга кадәр һәм аннан да артыграк күтәрелә.

Биектау районының Вахитов исемендәге колхозында арыш уңышы ашланмаган участкыда гектарына 16,5 центнер булды, ә 3,5 тонна известь кертелгән участкыда уңыш гектарга 23,7 центнерга җитте.

Татарстан республикасында сөрелә торган җирнең 50 процентка якыны көлсу туфраклы. Моның шактый өлеше һич кичекмәстән известьләнергә тиеш. Ә известьләү өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар. Туфракка известь кертергә тиешле колхозларның барында да диярлек исвесть яки известьлы кушылмалар бар. Мәсәлән, известь туфы үзенең нәтиҗәләре белән известь оныннан аз гына да калышмый.

Туфракны известьләүнең шундый өстенлекләре булуга карамастан, күп кенә җир органнары работниклары һәм колхоз җитәкчеләре тарафыннан бу чарага әле һаман тиешле бәя биреп җиткерелми. Шуның нәтиҗәсе буларак, республикада туфракны известьләү планы елдан-елга өзелеп килә. Бу план үткән ел да үтәлмәде.

Район. җир бүлекләре, МТС лар, бигрәк тә аларның агрономнары, колхоз җитәкчеләре известьләү эшенә бәя бирмәүне бетерергә, планның тулысынча һәм яхшы сыйфатлы итеп үтәлүен тәэмин итәргә тиешләр.

Колхозларда хәзердән үк известь хәзерләүне киң күләмдә оештырырга кирәк. Агрономнар известьне туфракка ничек һәм кайчан кертү, ничек саклау турында, аның әһәмияте турында аңлату эшләре алып барырга тиешләр.

Туфракның уңыш бирүчәнлеген күтәрүдә тирес, торф һәм башка җирле органик ашламалар гаять зур урын тоталар. Тирес авыл хуҗалыгында төп ашлама булып санала. Ул, туфракны туклыклы маддәләргә баету белән бер рәттән, аның физик, химик һәм биологик үзенчәлекләрен яхшырта. Торф һәм башка җирле ашламалар турында да шуны әйтергә кирәк.

Күпчелек колхозларда тирес саклагыч һәм тирес сыекчасы җыю урыннары юк. Шуның нәтиҗәсендә, бу кыйммәтле ашламаларның үсемлекләр өчен күп кенә туклыклы маддәләре югалып әрәм була.

Мондый хәл һичбер түзеп торырлык түгел. Һәрбер колхозда, терлекләр абзары янында тирес саклагыч, тирес сыекчасы җыю урыннары булдырырга кирәк.

Колхоз правлениеләре, бригадирлар колхозның җәмагать терлекчелегеннән алынган барлык тиресне тулысынча һәм дөрес файдалануны тәэмин итү белән бергә, колхозчыларның шәхси хуҗалыкларындагы тиресне файдалануны да оештырырга тиешләр.

Агроном — ***Х. Шаһиев.***

РӘСЕМДӘ: Кукмара МТС ының стахановчы бригадирлары. Сулда — район Советы депутаты С. Нургалиев һәм Н. Семенов иптәшләр. Алар 1940 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә кандидат булып торалар. А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 27 гыйнвар. (ТАСС). Кичә кич һәм бүген иртә белән Парижда иглан ителгән белдерүдә, фронтта әһәмиятле бер нәрсәнең дә булмаганлыгы күрсәтелә.

Гавас агентлыгы, һәр ике якның разведка очышлары үткәргәнлекләрен хәбәр итә. Каршы якларның эскадрильяләре арасында бәрелешләр булган, ләкин берсенең дә югалтулары булмаган.

БЕРЛИН, 27 гыйнвар. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе түбәндәгечә хәбәр итә: „Көнбатыш фронтта—разведка һәм артиллерия хәрәкәте. Германиянең хәрби диңгез көчләре бары тик 25 нче гыйнварда—бер көн эчендә генә дә каршы якның барлыгы 20 мең тоннадан артык авырлыктагы корабларын батырдылар. Моннан тыш Германиянең су асты көймәләреннән берсе Атлантик океанда Англия сугыш кораблары сакчылыгында бара торган ике пароходны батырды".

БРЮССЕЛЬ, 27 гыйнвар. (ТАСС). „Либр Бельжик" газетасының хәбәр итүенә караганда, Англиянең һәм нейтраль илләрнең Англия хәрби конвое белән тәэмин ителгән сәүдә корабларының саны 17 нче гыйнварга 6.872 единицага җиткән. Англия хәрби флоты сакчылыгындагы корабларның шушы санынннан 14 караб баткан.

Брюссельдә халыкара сәүдә институтының мәгълүматларына караганда, сугыш вактында, (15 нче гыйнварга кадәр) сәүдә флотының барлык югалтуы 950 мең тонна авырлыктагы 253 корабтан гыйбарәт булган.

ПАРИЖ, 27 гыйнвар. (ТАСС). Гавас агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 13 нче гыйнвардан 20 нче гыйнварга кадәр Франция флоты 9 корабны тоткан, 15.600 тонна товар басып алган. Сугыш башланганнан бирле 254 караб тотылган, 480.500 тонна товар алынган.

Крейгиның белдерүе турында Япониянең чит ил эшләре министрлеге

ТОКИО, 26 гыйнвар. (ТАСС). Япониянең кичке газеталары кичә Англиянең Токиодагы илчесе Крейгиның киң рәвештә булган белдерүен басып чыгардылар. Крейги бу белдерүдә, Япониянең „Асама—Мару" пароходын тоткан һәм герман пассажирларын кулга алган Англия крейсеры командасының хәрәкәтләрен акларга маташа.

Япония чит ил эшләре министрлегенең информация бүлеге Крейгинең чыгышы уңае белән махсус белдерү иглан итте. Белдерүдә түбәндәгеләр әйтелә: „Крейгинең белдерүе—ул, бары тик Англия ягының гына карашы булып тора, һәм без бу белдерүне Япония нотасына Англиянең чын җавабы дип таный алмыйбыз.

Япония хөкүмәте Англия хөкүмәтеннән рәсми җавап көтте. Шундый мөһим мәсьәләдә бары тик матбугат өчен булган белдерү белән генә эшне бетерү шикелле башка бер хәлнең бер вакытта да әле булганы юк иде. Англиянең мондый позициясе бөтенләй аңлаешсыз. Япония—Англия мөнәсәбәтләре карашыннан без бу факт уңае белән бары тик бик зур тәэссеф кенә белдерә алабыз".

ЛОНДОН, 26 гыйнвар. (ТАСС). Рейтер агентлыгының радио буенча хәбәр итүенә караганда, бүген иртә белән Англиянең Токиодагы илчесенә, Япониянең „Асама—Мару" пароходының Англия крейсеры тарафыннан тотылуы уңае белән Япониянең протест нотасына Англия хөкүмәтенең җавабы җибәрелгән. Англия илчесе Япония хөкүмәтенә бу җавапны мөмкин кадәр тиз вакыт эчендә тапшырачак.

Көньяк Африка союзы парламентында фикер алышулар

ЛОНДОН, 27 гыйнвар. (ТАСС). 23 нче гыйнварда Кептаунда Көньяк Африка Союзы парламенты утырышында оппозиция лидеры—Көньяк Африка Союзының элекке премьер-министре Герцог речь белән чыкты. Ул: „Германиягә каршы сугышны туктатырга һәм тынычлык урнаштырырга вакыт җитте" дип белдерде. Германиягә һәм Германия халкына каршы сугыш,—ди Герцог,—„халыкара үтерүчеләр һәм талаучылар" тарафыннан эшләнгән җинаяттән башка нәрсә түгел ул. Герцог,—Көньяк Африка Союзының Германиягә сугыш иглан итүе гаять зур ялгыш булып тора, ди. Герцог парламентка, Германия белән солых төзүне таләп итә торган резолюция кертте.

Герцог тарафыннан кертелгән резолюция буенча барган фикер алышуларда Көньяк Африка Союзының оборона хәле кискен рәвештә тәнкыйть ителде. Парламент члены Покок, Көньяк Африка оборонасы ышанычсыз хәлдә тора ди. Үз вактында оборонаның элекке министре Пироу, Көньяк Африка Союзы 150 мең солдат бирә ала, дип мактанган иде. Бу солдатлар коралсыз һәм киемсез хәлдә булып чыктылар. Сугыш башлануга ил хәзерге заман самолетларын да, җитәрлек санда сугыш кирәк-яракларын да хәзерләмәде, ди Покок.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Чжэцзян провинциясенең төньяк өлешендә Сяошань районында, япон гаскәрләре һөҗүм башладылар. Бу һөҗүм кытай гаскәрләре тарафыннан кире кайтарылды. Кытай частьләре Линбуны (Сяошаньнан көньякка таба 18 километрда) японнардан тазартып, чигенүче японнарны куып баралар. Хәзер кытайлар Линбу белән Сяошань арасындагы юл урталыгында. Японнар, кытай гаскәрләренең алга баруын туктату өчен, самолетлардан көчле рәвештә бомбага тоталар.

Шаосин районында кытай гаскәрләре японнарга шулай ук гаять зур зарар китерделәр.

Хубэй провинциясенең төньяк өлешендә япон гаскәрләре Тунбошань дигән таулы районны алырга маташалар. Ләкин, кытайларның көчле каршылыгына очрап, үзләренең элекке позицияләренә чигенергә мәҗбүр булдылар.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Шаньси провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлешендә кытай гаскәрләре Гаопинны (Чжанцзидән көньякка таба 40 километрдагы зур пункт) японнардан тазарттылар. Японнар Чжанцзыга һәм Луаньгә таба чигенәләр.

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә кытай һәм япон гаскәрләре арасында Наньниннан көньяк-көнбатышка таба 20 километрда сугышлар бара.

ШАНХАЙДА ЗАБАСТОВКАЛАР

ШАНХАЙ, 27 гыйнвар. (ТАСС). „Чайна Пресс" газетасы, рәсми мәгълүматларга караганда, халыкара сеттельмент территориясендә урнашкан предприятиеләрдә декабрь аенда 20 забастовка булганлыкны һәм аларда 8.787 эшче катнашканлыкны хәбәр итә. Забастовкалар гомумән алганда 29.687 көн (эш көннәре) дәвам иткән. Башка предприятиеләрдә бу срок эчендә эшчеләр белән хуҗалар арасында 28 конфликт булган.

Газеталарның хәбәр итүләренә караганда, „Исән раббер" дигән резина фабрикасының 500 дән артык эшчесе хезмәт хакын кыскартуга каршы протест билгесендә кичә итальян забастовкасы иглан иткән.

КАНАДА ПАРЛАМЕНТЫ ТАРАТЫЛДЫ

НЬЮ-ЙОРК, 27 гыйнвар. (ТАСС). Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, канадада Англия генерал-губернаторы лорд Туидсмюр, Канада парламентының утырышын ачкан вакытта, хөкүмәтнең иң якын киләчәктә гомуми сайлаулар билгеләгәнлеген иглан иткән. Хөкүмәт даирәләрендә, сайлаулар 4—6 атнадан соң булыр дип уйлыйлар.

Ассошиэйтед Пресс агентлыгының соңгы хәбәрләренә караганда, Канада хөкүмәте 25 нче гыйнварда 1 нче утырыштан соң ук парламентны таратkan.

РӘСЕМДӘ: Сталинчыл Өченче Бишьеллык исемендәге социалистик ярыш алдынгысы, торпедачы комсомолец иптәш В. П. Гончаренко (Кара диңгез флоты).

П. Совченко фотосы (ТАСС фото-клишесе).

ГСО значокларына нормалар тапшыралар

Арча районында 54 урында РОКК ның башлангыч оешмалары бар. Ул оешмаларда меңнән артык кеше член булып тора. РОКК членнарыннан 800 кеше ГСО значогының беренче баскычына, 30 кеше икенче баскычына һәм 150 бала БГСО значогына нормалар тапшырдылар.

РОКК ның „Кызыл почмак" колхозындагы башлангыч оешмасы яхшы эшли. Бу оешманың председателе Тәзкирә иптәш Нуриева колхозчылар арасында РОКК оешмасының бурычлары, ГСО значогына нормалар тапшыруның әһәмияте турында аңлату эшләре алып бара. Һәм бу эш үзенең яхшы нәтиҗәләрен бирә. Быелның гыйнвар аенда гына да РОКК членнарыннан 19 кеше ГСО значокларына нормалар тапшырдылар. Колхоздагы барлык допризывниклар ГСО значоклары алдылар.

Субаш Аты, Наласа, Яңа Сала авылларындагы башлангыч оешмалар да үзләренең эшләрен шактый яхшырттылар. Аларда яңа членнар саны һәм норма тапшыручылар саны көннән-көн арта бара.

Хәрби-диңгез эше инструкторлары хәзерләү

Осоавиахимның Казан диңгез клубында хәрби-диңгез эше инструкторлары хәзерләү буенча 3 айлык курсларның эше тәгәлләнде. Шушы көннәрдә чыгарыш булды. Укучылардан, студентлардан һәм эшчеләрдән 20 призывник-комсомолец инструктор хокукын алдылар.

Курс бетереп чыгучылар арасында 15 нче номерлы мәктәпнең 8 нче классында укучы Борис Аполонов, 83 нче мәктәпнең 8 нче классында укучы Борис Сметанин һ. б. бар.

Февраль башында 10 кешелек икенче группа укуларны тәмам итә. (ТатТАСС).

Потребкооперация работниклары ярышы

Татарстанның потребкооперация работниклары, профсоюз членнары арасында үзешчәнлек сәнгатен җәелдерү буенча Кырымның потребкооперация работниклары белән ярышалар. Ике арада төзелгән ярыш договорында, түгәрәкләр оештыру белән бер рәттән, тәҗрибәләрне уртаклашу өчен художество смотрлары һәм башка чаралар үткәреләчәге турында күрсәтелә.

Ярыш договорын үтәү йөзеннән күптән түгел генә Кырымның сәнгать бригадасы Казанда булды. Совет Сәүдәсе Работниклары клубында барган смотрда Кырымның һәм Татарстанның сәнгать бригадалары чыгышлары булды. Тәҗрибәне уртаклашу теләге белән үткәрелгән бу очрашу милләтләрнең чын дуслык бәйрәме булып үтте.

1940 нчы елда Татарстанның сәнгать бригадасы Кырымга барачак.

Лекцияләрне 161.613 кеше тыңлады

Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты янындагы лекцияләр бюросының лекторлары тарафыннан 1939 нчы елда төрле темаларда 1.503 лекция укылды. Бу лекцияләрне 161.613 кеше тыңлады. Шуларның 1.012 се Казанда укылып, аларны 102.393 кеше тыңлады.

Лекцияләр халыкара хәл, партия тарихы, сайлаулар тәртибе һәм Сталин Конституциясе турында, шулай ук, әдәбият, диңгә каршы пропаганда, хәрби-тарихи һәм фәнни-популяр темаларда үткәрелде. Лекцияләр бюросының лекторлары Татарстанның 10 районында булдылар. Шулай ук күрше Мари республикасына барып та лекцияләр укыдылар. 1939 нчы елда Казанда беренче тапкыр буларак түләүле лекцияләр үткәрелә башлады. Лекцияләргә халык зур кызыксыну белән йөри.

1940 нчы елда лекцияләрнең санын һәм сыйфатын тагын да яхшырту күздә тотыла.

Страхование буенча 1 миллион сум акча түләнде

Тормышларын ирекле рәвештә страховать итүчеләрнең семьяләренә дәүләт страхованиесе 1939 нчы елда 1 миллион сумга якын акча түләде. Страхование взносы түләү квартал саен артып бара. Ләкин урыннарда бу эшкә әһәмият бирмәүче оешмалар да бар әле. Мәсәлән, Казкинохимстрой, киез итек фабрикасы, Кинопленка, 2 нче һәм 5 нче номерлы тегү фабрикалары, Казан пристане һәм башкаларның фабзавкомнары һәм месткомнары үзләрендә эшләүчеләрне страховать итү эше белән шөгыльләнмиләр.

Татар совет әдәбияты һәм сәнгате 10 көнлегенә хәзерлек

Татарстан Совет Язучылары Союзы татар әдәбияты һәм сәнгате 10 көнлегенә хәзерләнә. 10 көнлекне СССР Совет Язучылары Союзы оештыра һәм ул Москвада үткәреләчәк.

Татар совет әдәбияты һәм сәнгате 10 көнлегендә катнашу өчен үзләренең әсәрләре белән татар Совет язучылары, шагыйрьләре, драматурглары, артистлары һәм халык фольклоры вәкилләре Москвага барачаклар.

Яңа ферма оештырылды

Кызыл Юл районы, Куйбышев исемендәге колхозның (Яңа Өҗем авылы) колхозчылары ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм СССР Совнаркомының „колхозларда җәмәгать терлекчелеген үстерү чаралары" турындагы карарын өйрәнгәннән соң, сыер асраучылык фермасы оештырдылар. Фермада хәзер 16 баш тана бар. Фермада эшләү өчен колхозның иң алдынгы колхозчысы Гөлсем иптәш Вәлеева куелды.

Таналарның тору урыннары чиста һәм җылы. Алар өчен җитәрлек азык хәзерләнде.

Г. Исмагыйлов.

„Строитель" спорт җәмгыятенең Бөтенсоюз ярышы

„Строитель" спорт җәмгыяте Казанда 28—30 нчы гыйнварда чаңгыда йөрү буенча Бөтенсоюз ярышлары үткәрә. Ярышларда Москва, Ленинград, Минский, Мурманский, Куйбышев, Чебоксар, Ижевский, Йошкар-Ола һәм Казан командалары—барлыгы 100 гә якын кеше катнашачак. Болар арасында—50 процент хатын-кызлар.

КОЛХОЗЛАРДА СТАХАНОВЧЫЛАР МӘКТӘПЛӘРЕ

Чепья районының 12 колхозында стахановчылар мәктәпләре оештырылды. Аларда хәзер 300 дән артык колхозчы стахановчы укый. Стахановчылар мәктәпләрендә агротехника, татар теленең рус графикасы нигезендә төзелгән яңа алфавиты, партия һәм хөкүмәт карарлары өйрәнелә, лекцияләр укыла. Стахановчылар бу лекцияләрне яратып тыңлыйлар.

Киров исемендәге колхозда 52 яшьлек Рахматулла иптәш Нигмәтуллин аеруча агротехниканы үзләштерү белән кызыксына. Яңа алфавитны һәм орфографияне өйрәнү буенча да укулар күңелле үтә. Укытучы Гафиулла иптәш Гарифуллин дәрескә яхшы хәзерләнеп килә.

Ф. Гафиятуллин.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

„ТРАНСЭНЕРГОКАДР" НЫҢ КАЗАН БҮЛЕГЕ

КОЧЕГАРЛАР хәзерләү буенча шушы ел, 1 нче февральдән (уку срогы 2 ай, укыту өчен түләү 271 сум),

ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР хәзерләү буенча 10 нчы февральдән (уку срогы 3 ай, укыту өчен түләү 408 сум) һәм локомобильләр, шулай ук пар машиналары өчен

МАШИНИСТЛАР хәзерләү буенча 10 нчы февральдән (уку срогы 2 ай, укыту өчен түләү 408 сум)

УКУЧЫЛАР АЛА

Курсларга предприятиеләрдән бирелгән командировкалар белән генә алына. Казан, Банк урамы, 15. 152—2—1

КАЗАН ШӘҺӘР ТРАМВАЙ ИДАРӘСЕ

кондукторлар, вагон йөртүчеләр һәм слесарьлар хәзерләү курсларына

УКУЧЫЛАР АЛА

Уку сроклары: кондукторлар хәзерләү курсларында—20 көн. Стипендия айга 75 сум. Вагон йөртүчеләр курсларында—ике ай ярым. Стипендия айга 90 сум. Слесарьлар хәзерләү курсларында—2 ай. Стипендия айга 90 сум.

Курсларга 18 яшь тулган һәм аннан югары яштәге кешеләр кимендә 4 класс күләмендәге белем белән алыналар. Ялгызларга, медицина тикшерүе комиссиясе үткәннән соң тулай торакта урын бирелә.

Гаризалар шушы ел, 1 нче февральгә кадәр алына. Документлар белән гариза җибәрү өчен адрес: Казан, Ершов кыры, 1, бүлмә № 6. 121—3—2

Казан тимер юлының санитария бүлегенә, курсантларны урнаштыру өчен,

БҮЛМӘЛӘР һәм почмак урыннар КИРӘК

Казан, Посадский урамы, 14. Кадрлар бүлегенә килергә. 160—1

Галиәсгар Камал исемендәге

Татар Дәүләт Академия театры

29 һәм 30 нчы гыйнварда спектакльләр булмый.

31 нче гыйнварда, шулай ук 1 һәм 2 нче февральдә ПРЕМЬЕРА

БУЛАК АРТЫ „РЕСПУБЛИКАСЫ"

Талоннар: 105, 106 һәм 107.

Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

29 нчы гыйнварда

РЕВИЗОР

Бүген талон 87.

30 нчы гыйнварда көндез һәм кич (талоннар: 18 һәм 88), 1 нче февральдә

БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА

Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 8 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Москва 4 нче труппасының соңгы гастрольләре

ИНТЕРМЕДИЯ

ЧИК ЙОЗАКТА

РСФСР ның атказанган артисты орденлы

М. ЗОЛЛО үзенең антропозоологик труппасы белән

Атнаның икенче көнендә цирк эшләми.

Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

Татар Дәүләт Опера театры

(Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры бинасында)

БҮГЕН ТАТАРСТАН АССР НЫҢ АТКАЗАНГАН АРТИСТКАСЫ—

Мәрьям Рахманкулова

КОНЦЕРТЫ

Программа татар телендә башкарыла. Сезонлы урыннарга 69 нчы талоннар белән кертелә.

Кич 9 да башлана.

Зур Драма театры филиалы

(Киров районындагы Культура сарае)

Татар Дәүләт Академия театрының 29 һәм 30 нчы гыйнварга билгеләнгән спектакльләре—

БИШБҮЛӘК башка көннәргә күчерелә

Спектакльләрнең куелу көннәре турында иглан ителер.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 12-30, 2-45, 7-45 һәм 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
„УНИОН" 11, 1-20, 3-40, 6, 8-20, 10-30 да.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	ДУСЛАР
„Колхозник" 6, 8 һәм 10 да.	БАЙ КӘЛӘШ
„ЧАТКЫ" 6, 8 һәм 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
„ПИОНЕР" 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Көндез ПОЕЗД МОСКВАГА БАРА Кич УКЫТУЧЫ Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ" 4, 6, 8, 10 да.	ДОКТОР КАЛЮЖНЫЙ
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	Степан Разин

А. П. ЧЕХОВ

(Туына 80 ел тулу уңае белән)

Чехов заманындагы җәмгыяттә ике йөзлелек, кешелек дәрәҗәсен мыскыллау, деспотизм, тупаслык, ялагайлык һәм башка шуның кебек әшәке гадәтләр хөкем сөрә иде.

Үзенең балалык вактын агулаган шушы начарлыкларга каршы Чехов рәхимсез көрәш башлый. Үзенең беренче әсәрләрендә үк Чехов әшәкелекнең, коллыкның конкрет гаепләләрен күрсәтә. Ул аларны үзенең шәхси дошманнары сыйфатында фаш итә, шуның белән бергә, ул, Россияне изеп килгән кара көчләрне хурлык баганасына бөтен халыкның мәсхәрәләвенә куя.

Алыйк „Ванька"ның җанлы балалык омтылышы герое Ваняны. Аның гади генә итеп язылган, ләкин ачы хәсрәт белән тулган хаты бабасына барып җитә алмаган кебек, капиталистик җәмгыяттә аның омтылышлары да бер кайчан да эшкә ашмаячаклар.

„Тормыш вак-төякләре" дигән хикәядәге малай—Алеша—бала булганлыктан алданган. Ләкин „Авыр кешеләр" дигән хикәядә балаларның гына түгел, олыларның да алданулары күрсәтелә.

„Хамелеон", „Маска", „Юан һәм нәзек" кебек хикәяләр ялагайлык рухын фаш итәләр. Илнең бөтен халкы, дәрәҗәләр турындагы табель буенча хуҗаларга һәм колларга бүленгән иде. Ул замандагы тормышның символик хуҗасын, гомуми катып калуны тәртип һәм тынычлык идеалы дип санаучы унтер Пришибаевны кем хәтерләми! Ул заманның мәктәбен, чыннан да, коллык мәктәбен Чехов „Футлярдагы кеше" дигән хикәясендә аеруча рәхимсезлек белән фаш итә. Хикәянең герое—„берәр хәл килеп чыкмагае" дип өзлексез куркып яшәгән укытучы Беликов—бөтен шәһәр халкын куркытып тотмакчы булган һәм үзе куркудан үлгән.

Патша Россиясендәге кара көчләрнең йөзләре никадәр генә күп төрле булмасын,

Чехов алардагы уртаклыкны күрсәтә алды. Бу уртаклык—кешелек дәрәҗәсенә бик аз гына булса да ихтирам хисенең юклыгыннан һәм обывательләр арасында интересларның һәм омтылышларның әшәке характерда булуыннан гыйбарәт иде.

Дәрәҗәсе ягыннан үзеннән өстен булган һәрбер кешедән, үзенә бәйле булган кешеләргә тупас кыланучы кешедән гомере буена куркып яшәүче куян йөрәкле обывательне Чехов үзенең уникарча хикәяләрендә ачык чагылдырды. Патша Россиясенең хуҗалары халыкны көндәм итеп тоту өчен аны гасырлар буена әнә шулай куркыту белән „тәрбияләп" килделәр.

Соңга табарак Чехов үзенең киң һәм катлаулы әсәрләрен, типларының җанлы һәм дөрес булулары ягыннан рус тормышының искиткеч картиналарын тудырды. Аның „Дуэль", „Палата №6", „Минем тормышым", „Мужиклар", „Ариадна", „Үтерү", „Футлярдагы кеше", „Өч ел" кебек хикәяләре әнә шундыйлар. Бу әсәрләрнең һәрберсе матбугатта җанлы фикер алышулар тудырды, аларның күпләре, мәсәлән, „Мужиклар", „Чокырда" хикәяләре көчле дискуссияләргә сәбәп булдылар.

А. И. Ульянова—Елизарова үзенең „Ильич турындагы истәлекләр" дигән китабында болай дип яза: „Ул кышны журналларның берсендә А. Чеховның „Палата №6" дигән яңа хикәясе басылып чыккач, Володя белән булган сөйләшүем хәтеремдә калган. Бу хикәянең талантлы икәнлеге турында, анардан алынган көчле тәэсир турында әйтеп,—Володя, гомумән, Чеховны ярата иде,—ул бу тәэсирне түбәндәге сүзләр белән барыннан да яхшырак итеп аңлатып бирде: „Кичә кич белән бу хикәяне укып бетергәч, мин эсселе-суыклы булып киттем, мин бүлмәмдә кала алмадым, урынымнан тордым да чыгып киттем. Мин үземне дә 6 нчы номерлы палатага ябылган итеп хис иттем".

Билгеле, революциягә кадәрге күңелсез һәм авыр тормышны күрсәткән „Палата №6" хикәясен һәммә кеше дә Ленин кебек ачык итеп аңламады. Ләкин укучыларның күбесе Ленин кичергән хисне кичерделәр һәм монда Чеховның укучылар белән ныклы элемтәсе урнашты. Бу бигрәк тә җәмгыят күтәрелеше һәм соңыннан бу күтәрелешнең 1905 нче елгы революциягә әйләнеп китүе чорында күренде.

Чехов 1904 нче елны, үзенең иҗад куәте гөрләп чәчәк атканда үлде. 1898 нчы елны ук, аның иң яхшы әсәрләре чыкканчыга кадәр ук инде, Горький Чеховка болай дип язган иде:"... Сез—искиткеч көчле талант... Рус әдәбиятында әле сезнең кебек новеллист булганы юк иде, ә хәзер сез бездә иң кыйммәтле һәм иң эре фигура. Мопассан яхшы һәм мин аны бик яратам, ә сезне аннан да артыграк яратам. Гомумән, мин сезгә олылавымны ничек аңлатырга белмим, сүзләр таба алмыйм һәм — ышаныгыз! Мин чын күңелдән әйтәм. Сез куәтле талант".

Рус әдәбияты үсешендә Чеховның роле чыннан да гаять зур. Ул, кыска, ләкин тирән эчтәлекле новеллалар тудырды. „Настроение драмасы" дип аталган нәрсәне тудырып, ул драматургия өлкәсендә чын переворот ясады. Чехов үсеп җиткән вакыттагы театр репертуарында бары тик тышкы вакыйгалар һәм хәлләр генә күрсәтелә иде. Чехов пьесалары театрга яңа агым керттеләр. Чехов пьесаларының геройлары кычкырмыйлар, буталышмыйлар, сәхнә буйлап йөгереп йөрмиләр. Алар үзләрен сәхнәдә тормышта тоткан кебек тоталар.

Рус язучысына карата булган иң югары мактауны Чеховка ул үлгәннән соң Лев Толстой күрсәтте. Ул аны Пушкин белән янәшә куярга уйламады, ләкин болай диде: „Чехов!... Чехов — ул, прозада Пушкин. Пушкин шигырьләрендә һәрбер кеше үзенең башыннан кичкән хәлләрдән кайсын гына булса да таба алган кебек, Чехов хикәяләрендә дә... укучы һич шиксез үзен һәм үзенең фикерләрен күрәчәк..."

Чехов — безнең илебездә иң сөекле һәм иң күп укыла торган язучыларның берсе.

А. Д.

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 228 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 392.